ISSN 0868-4545




# Салават күпере



# Игътибар! Бәйге дәвам итә!

## Шүрәле малае Шүркә



Борын-борын заманда түгел, кичә дә түгел, иртәгә дә түгел... Кыскасы, бер мактанчык малай яшәгән ди. Исеме Шамил булган. «Мин болай да акыллы!» – дип, хәтта мәктәптәге дәресләрен дә калдыра икән ди. «Укы! Акыллы булырсың!» – дигән аңа өлкәннәр. «Укымыйм! Мин болай да акыллы!» – дип җавап кайтарган малай. «Мәктәпкә йөр, дәресләреңне калдырма, өйгә укытучы биргән биремне яхшылап эшлә! Акыллы булырсың!» – дигәннәр аңа. «Дәресләрдән качам, өйгә бирелгән эшләрне эшләмим! Мин бит болай да акыллы!» – дигән малай.

Авыл кырыенда гына урман булган. Ул урманда бер Шүрәле малае яшәгән, аның исеме Шүркә булган. Менә шул Шүркә «Урман мәктәбе»ндә укый икән. Дәресләрне калдырмый, бик тырышып укый ди Шүркә. Тырышып укыгач, ул Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкиятен дә яхшы белгән инде. Ә безнең надан, әмма мактанчык танышыбыз Шамил «Шүрәле» әкиятен дә укымаган, ди. Һаман мактануын белә, ди. «Мин урманга барам да, Шүркәне койрыгыннан каптырам да, мөгезеннән тотам!» – ди, имеш.

Берзаман Шамилебез чынлап та урманга киткән. Шүркәне кызык итәргә уйлаган, ди ул.

*Укучым!*

*Без әкиятне яздык, син аны үзеңчә дәвам ит. Иң яхшы әкиятләргә, иң уңышлы хатларның авторларына – бүләк-призлар!*

*Жюри өч авторның иң яхшы эшен сайлап алачак! Һәм өч кешегә дә компьютер бүләк итәчәк!*

*Димәк,*

## *Беренче өч урынга - компьютер!*

*Бүләкләрне «Салават күпере» синең өеңә яки мәктәбеңә илтеп тапшырачак. Редакциягә үзеңнең килеп алырга мөмкинлегең булмаса инде әгәр...*

*Конкурска йомгак киләсе 2009 елның апрель аенда ясалачак. Син ул хакта «Салават күпере» битләреннән укырсың.*

## *Уңышлар сиңа!*

*«Салават күпере».*

# Шүркә белән очрашу

Берзаман Шамил чынлап та урманга киткән. Шүркәне кызык итәргә уйлаган ди ул.

Урман буйлап барганда, очраган ди аңа бүре. Шамил:

– Кем син, Шүрәле малаемы? – дип сораган.

– Мин – бүре, маңгаемда мөгез күренмидер бит? – дигән дә, тешләрен ыржайтып, көлеп җибәргән.

Шамил куркуыннан чабарга тотынган. Чаба торгач, Шамил агач башында чикләвек чыртлатып утыручы тиенне очраткан.

– Синме инде ул Шүрәле малае? – дип сораган Шамил тиеннән.

– Мин нинди Шүрәле малае булыйм, көлдермә инде! Мәктәптә нәрсәгә генә өйрәтәләр соң сине? Мин – тиен!

Шамил аптырап тагын сукмак буйлап атлаган. Бара торгач, аңа Шүрәле малае очраган.

– Маңгаеңда мөгезең дә бар икән, син Шүрәле малаедыр инде. Бөтен кеше сине мактый: бик акыллы, тәртипле, мәктәптә бик тырышып укый, диләр. Мин урманга сине күрер өчен килдем, синең белән сөйләшәсем, аңлашасым килде. Син ни өчен мәктәпкә укырга йөрисең, без бит болай да акыллы, – дигән Шамил.

Шүрәле малае аны тыңлап торган да:

– Син нишләп үзеңне акыллы дип әйтәсең, үзең бөек шагыйребез Габдулла Тукайның «Шүрәле» исемле әкият-поэмасын да белмисең. Менә мәктәп нәрсәгә өйрәтә: «Белем – нур, белмәү – хур ул, дускаем», – дигән һәм Габдулла Тукайның «Шүрәле» поэмасын яттан сөйләгән.

Шамил шул көннән башлап мәктәпкә укырга бара башлаган. Барлык дәрестә дә катнашып, барысын да үзләштереп, тәртипле, үрнәк укучыга әверелгән.

Булат НИГЪМӘТУЛЛИН, 10 яшь.
Арча, Яңа Кенәр.






Илнар ХӘБИБУЛЛИН. Зәй, Чыбыклы.

# Шүрәле малае Шүркә

Китә Шамил Шүркәне эзләп! Бара торгач, Шамил сөйләшкән тавышлар ишетә. Игътибар белән карасa, үзләре кешегә охшаган, ләкин бөтен гәүдәләре йон белән капланган, маңгайларында сыңар мөгезе булган куркыныч җан ияләре утын кисеп ята икән. Шамил курыкса да, бөтен кыюлыгын җыеп, болар янына килә:

– Кайсыгыз Шүркә була, әй, шыксыз җан ияләре? – ди.

Башкаларга караганда кечерәк мөгезле, кечерәк гәүдәле бер Шүрәле малае алга килеп чыга. Шүркә үзенең әти-әниләренә кышка ягарга утын әзерләшүен, урманда бер генә җан иясенең дә эшсез ятмаганын, укымыйча тик йөрмәгәнен сөйләп бирә. Шүркә Шамилгә үзләренә булышуын үтенә.

– Әйдәле, Шамил дус, көчебез җитмичә аптырап тора идек. Шушы юан бүрәнәне арбага салыш әле, – ди. Ә үзе бүрәнәнең ярыклы башын Шамилгә күрсәтә. Шамил, аны-моны уйлап тормыйча, ярыктан барып тота. Шүркә бүрәнәнең үз башындагы чөен тартып та ала. Шамилнең кулы агач ярыгына кысылып кала.

Әй авырта Шамилнең куллары, әй кычкыра ул.

– Ычкынсам, тырышып укыр идем, укытучыларның сүзләрен тыңлар идем, – дип, әй елый Шамил.

Аның тавышына Шүрәлеләр җыела.

– Тукайның «Шүрәле» әкиятен дә укымыйча, Шүркәне кызык итеп булмый шул, әй, аңгыра, юләр малай! – дип көлә шүрәлеләр.

– Укымаганга былтыр, кычкыралармы быел? – ди Шүрәле малае Шүркә.

Урманга барып, Шүркәне койрыгыннан каптырам да, мөгезеннән тотам, дип мактанган Шамил Тукайның «Шүрәле» әкиятен белмәве аркасында көлкегә кала.

Раил ГАЛИЕВ, 11 яшь.
Арча, Ташкичү.






*Нәфис ЗАРИПОВ, 12 яшь. Актаныш, Кыркаентүбә.*

# Адашкан шигырьләр, буталган рәсемнәр

*Күрәсезме, шигырьләр дә адашкан, рәсемнәр дә буталган.*

*Кайсы шигырь нинди рәсемгә туры килә? Туры килгән шигырь белән рәсем янындагы шакмакны берүк төскә буя.*



Йомгак кебек йомшак ул,
Сыйпаганны ярата.
Ә үзе шундый усал
Тычканнарга карата.








Рәсем ясый һәр бала,
Кулларында пумала.

Чабып китсә тыпырдап,
Тотармын димә кабат.
Кешеләрнең дусты ул,
Ә исеме аның ...









Колагым шәп ишетә,
Исне әйбәт сизәмен.
Хуҗам чакырса әгәр,
Бик тиз барып җитәрмен.

Зилә рәсемнәре




МӨҖӘҺИТ

# Табышмак әйтәм...


Җәй дә үсә, кыш та үсә,
Тамырлары – түбәндә.
Ул һәрвакыт югарыда,
Ә без аннан түбәндә.

(Чәч)



Керләр өстеннән үтә,
Шуннан... эше дә бетә.

(Үтүк)



Кызлар карап туя алмый,
Карыйлар да карыйлар.
Аңа карап елмаялар,
Йә чәчләрен тарыйлар.
Кайчак аңа малайлар да
Карап-карап алгалый.
Хәтта әби-бабайлар да
Яшертен күз салгалый.

(Көзге)

Чакырмыйм да, алмыйм да,
Бер адым да калмый да.
Ике, өч, күп тә була.
Тәрбиясез булсагыз,
Ул чүп-чар белән тула.

(Кесә)

Бәреп-сугып йөртәләр,
Капкаларга кертәләр.

(Алка)







Башта күктә очып йөри,
Аннан җиргә елыша.
Тизрәк тотып калабыз, дип
Балалар җыелыша.

(Кар)

Барыбызга да килә ул:
Миңа да, Илшатка да.
Сыерга да, кәҗәгә дә,
Тавыкка да, атка да.

(Йокы)

Яратмаса да алалар
Аны кайбер балалар.

(«2»ле)







Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,
Кайчак кара төстә мин.

(Болыт)

Рәшит ЯГЪФӘРОВ

# Кем урлаган тарыны?

Борын заман бер әтәч
Башына кигән, ди, кәпәч.
Тубал аскан иңенә,
Киткән чәчү җиренә.
Чәчкән, ди, әтәч тары –
Ун гектарлап нибары.




Чебешләрен ияртеп,
Килеп җиткән тавыгы.
Тавык җирне үлчәгән,
Чеби тары чүпләгән.
...Ярый, җәйләр дә үткән,
Көзләр дә килеп җиткән.
Әтәч киткән басуга,
Урак тотып кулына.
Күп йөргән уңга-сулга –
Бер тары юк басуда.
«Китереп куй! – дип кычкырган, –
Әй, кем урды тарыны!
Кемнәр урлаган тарыны –
Ярылгыры карыны!»
Кем урлаган тарыны дип,
Шаккаткан, ди, тавыгы.
Яле, син дә уйлап кара –
Кем урлаган тарыны?

# Бардым урманга

Шулай бер заман
Киттем урманга.
Күсе җигеп фурманга,
Җиләк-җимеш җыярга.
Килеп керсәм урманга –
Нәрсә генә юк анда.
Исем китте шул чакта –
Алма пешкән усакта.
Юкәдә пешкән җиләк,
Җыеп алдым бер күнәк.
Чыршыда үскән балан,
Имәндә пешкән банан.
Чаганда пешкән миләш,
Торалар тәлгәш-тәлгәш.
Шомырт пешкән зиректә,
Җыеп алдым чиләккә.
Элмә үскән... шундый зур,
Ботак саен помидор.
...Булдым шундый урманда,
Нәрсә генә юк анда,
Барсын төяп тубалга,
Кайтып киттем урманнан.
Чокыр саен сикәлтә,
Күсе артын сикертә,
Сибелеп калган бар җимеш.
Өйгә кайткач карасам,
Бер җимеш тә юк, имеш.

*Рәссам Диләрә НӘҮРҮЗОВА*







*Журналыбызның 10 нчы санында (2007 ел) «Көз һәм Яз турында инша языгыз», – дигән идек. Журналханәгә килгән бихисап хатларның кайберләре белән танышыйк әле. Хат авторларына истәлекле бүләкләр юллыйбыз.*

*Шундый бүләкләрне түбәндәге укучыларыбызга да ирештерәбез:*

*Ләйсән Хәсәншина, Чулпан Гайнетдинова, Светлана Бохарина, Йолдыз Нуруллина, Ләйсән Галимҗанова (Арча, Яңа Кишет), Чулпан Кирамова (Мөслим, 2 нче мәктәп).*

*Уңышлар телибез Сезгә, дуслар!*



*Регина МӨХЕТДИНОВА, 8 яшь.*
*Чүпрәле, Иске Чүпрәле.*

# Яз белән Көз

Моннан күп еллар элек яшәгән, ди, булган, ди, бик дус ике кыз – Язбикә белән Көзбикә.

Язбикә үзенең гүзәллеге, җылылыгы белән бар дөньяны шаккатырган. Аны хәтта кояш үзе дә бик яраткан: көн дә, таң ату белән, җылы нурларын бүләк итеп җибәргән. Язбикәгә кошлар да бик сөенгәннәр: аның иңенә кунып, сандугачлар тәүге җырларын җырлаганнар. Ул узган җирләрдә энҗе чәчәкләр, умырзаялар калкып чыккан, агачлар бөрегә күмелгән, ди.

Ә Көзбикә исә үзенең шаянлыгы белән дан тоткан. Ул тиктормас җилкәй, юеш болытлар белән бик дус булган. Алар һәрвакыт бергә уйнаганнар. Көзбикә бик юмарт булган, ди. Ул һәрбер җан иясенә алсу алмалар, татлы грушалар, бихисап күп җиләк-җимеш тараткан.

Нәфисә АТАДЖАНОВА.
Мөслим, 2 нче мәктәп.



*Наилә һәм Наил ФӘЙЗРАХМАНОВЛАР,*
*8-9 яшь. Кукмара.*



*Камил ГАТИН, 8 яшь.*
*Кукмара, 2 нче мәктәп.*

# Мин көзне яратам

Һәрбер ел фасылы үзенә күрә матур, үзенә күрә искиткеч. Дүрт ел фасылы арасыннан мин көз айларын бигрәк тә яратам. Ни өчен көзне яратам соң? Көзге агачларга сокланам мин. Нинди генә төскә керми бит алар! Көз үзенең пумаласы белән агачларны сары, кызгылт-сары төскә буйый, ә агачларның үзенә нинди генә сусыл, тәмле җиләк-җимешләр элми ул. Агач төпләренә чикләвек коя, гөмбәләр утырта. Безнең аяк асларыбызга сары яфрак түшәргә дә онытмый әле ул. Яфрак яңгырларын яратам мин. Анда ниндидер серлелек бар. Көз ае агачларга утлы яктылык кундырса да, кайбер агачларның яфраклары коелырга ашыкмый. Алар усал җилләр чыкканын көтә. Без теләмәсәк тә, ул җилләр кошларны җылы якка куа. Ләкин без моңа борчылмыйбыз. Кошлар тиздән безгә ямьле язлар җиткәч әйләнеп кайтырлар...

Альмира ДӘҮЛӘТОВА, 11 яшь.
Саба, Сатыш.

# Яз, яз, яз җитә...

Менә гөрләвекләре белән яз килә. Кояш балкый, ул өй түбәләрендәге карларны эретә, көмеш тамчылар тама, карлар эри. Алар суларга әйләнеп, елгаларны уяталар. Тау битләре дә кардан ачыла. Һәр җирдә яз сулышы бөркелә. Кояш нурларын көннән-көн күбрәк чәчә. Язгы җылы җил агачтагы яшь бөреләрне уята. Тиздән алар хуш исле яшел яфраклар ярырлар.

Рания ИШМОРАТОВА, 10 яшь.
Арча, Урта Сәрдә.



*Алсу ГАЛИМҖАНОВА, 10 яшь.*
*Мөслим.*

# Җәнлекләр дә шатлана

Менә яз хәбәрчеләре – кара каргалар килеп, су буендагы биек талларга оя кордылар. Без сыерчыкларга оялар да ясап куйдык. Озакламый башка кошлар да кайтыр.


Яз килүенә хайваннар, җәнлекләр дә бик шат. Табигать җанлана, яшәрә. Кырларда язгы эшләр кайный. Көннәр җылынган саен, табигать көннән-көн гүзәлләнә бара.

Ләйсән ГАЛИМҖАНОВА.
Арча, Яңа Кишет.







Рузия, 8 яшь

– Күрегез, мин быел тагын
Бер яшькә үстем менә:
Кыш бабай, Кар кызы белән
Сурәткә төштем менә!

*Чүпрәле, Зур Чынлы.*



Марсель, 2 яшь 5 ай

– Буем җитми һич кенә –
Йөреп китәсе идем,
«Ә» дигәнче Казанга
Барып җитәсе идем!

*Балтач, Таузар.*



Инзилә, 4 яшь

– Клавишларга бармак белән,
Йодрык белән баскалыйм...
Тизрәк кәнфит бирмәсәгез,
«Уйнавым»ны ташламыйм!

*Чирмешән, Лашман.*






Эльмира, 10 яшь
Оля, 9 яшь

– Апаем, дим, апаем,
Җә, жылама, сөрт яшең!
Хәзер мәзәк сөйлимен –
Эч катканчы көләрсең...

*Сарман.*





Дима

– Иркенләп, бик җайлап,
Шешәмне имеп ятам:
«Тамак тук» дип, сөенеп,
Елмаеп-көлеп ятам!

*Пермь, Барда.*




– Бәбкәләрем минем янга
Җыйналдылар бүген дә...
«Пип-пип-пип!» – дим, шигырь сөйлим
Мин дә кошлар телендә.

*Түбән Кама.*

– Матур күлмәк кидем әле –
Бер үк күз тидермәгез...
Башны исәм – бантик төшә,
Башымны идермәгез!

*Удмуртия, Камбарка, Кама.*










– Роза гөле, роза гөле –
Бакчабызның бизәге...
Сине уйлап, җанкисәгем,
Өзелә бит үзәгем.

*Казан.*





– Дөньяга сокланып утырам
Чәчәкләр арасында:
Ходаем, гомерләр бирсәңче
Мин – татар баласына!

*Яр Чаллы.*









– Тагы бер ел үтеп китте –
Калдырды ул истәлек:
Фотосурәткә төштек без,
Икәүләшеп, хисләнеп!

*Кукмара, Вахит.*





*Бу матур рәсемнәрне 77 нче бакчада (Казан) тәрбияләнүчеләр ясаган.*



*Маша ЧАПЧИНА, 7 яшь.*



*Максат БӘЙРӘМГИЛЬДИЕВ, 6 яшь.*



*Алсу РӘХИМОВА, 6 яшь.*



*Настя ШАБАЛИНА, 5 яшь.*



## «Иске самавыр торбасы»

Журналыбызда (№ 10, 2007 ел) шагыйрь һәм язучы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Гәрәй Рәхимнең «Иске самавыр торбасы» дигән маҗаралы хикәятеннән бер өзек тәкъдим итеп, аның дәвамын язарга кушкан идек. Бик күп хатлар килде. Бу юлы без хикәятнең дәвамнарын журнал битләренә урнаштырып тормаска, ә бәлки авторларның исем-фамилияләрен генә күрсәтеп үтәргә һәм аларның барчасына да истәлекле бүләкләр җибәрергә булдык. Менә алар – безнең актив авторларыбыз: Римма ШӘЕХОВА (Азнакай), Фәридә ХӘМӘТДИНОВА (Мөслим, Вәрәшбаш), Зөлфинә һәм Гөлфинә ГАЗИЗОВАЛАР (Сарман, Җәлил бистәсе), Ризидә ХӘМӘТДИНОВА (Кукмара), Газинур ЛАТЫЙПОВ, Сергей САМОЙЛОВ, Гөлшат БАРИЕВА, Алсу ӘХМӘДУЛЛИНА, Динар ГОРЛАНОВ, Эльвира АТНАЛИНА (һәммәсе дә Мөслимдәге 2 нче мәктәптән, укытучылары – Гөлназ Фәнис кызы Гайнетдинова).




# Нияз мәзәкләре



## Нияз әйтә...

– Мин үскәч безнең өйдә ике әти була – мин, аннары минем әти...

– Мин кем булам соң, улым? – дип сорый бабасы.

– Син, бабай, гел бабай буласың, – ди Нияз.



## Ниязның уянуы

Иртә. Нияз караватында утыра. Уянган инде ул, күзләре генә ачылып җитмәгән. «Юындырыгыз әле күзләремне, тизрәк ачылсыннар!» – дип кычкыра ул бабасы белән дәү әнисенә.

## Нияз ашка бара

Ниязның дәү әнисе Коръән ашына барырга җыена. Ниязның да аның белән барасы килә. «Әппәр иткән әбиләр янына барам. Алдырыгыз инде минем тәһарәтемне. Бирегез инде матур киемнәрем белән түбәтәемне», – дип, бер адым да калмыйча, әнисе белән дәү әнисе артыннан ияреп йөри.




## Нияз әнисен көтә

Ниязның әнисе бәби тудыру йортында эшли. Аның эштән кайтуын Нияз, тәрәзәдән карап, көтеп тора. Әнисе озаграк торса: «Әни безгә алып кайтырга бәби сайлыйдыр инде», – дип әйтеп куя.

## Нияз ник йокламый?

Өйдә утлар сүнгән. Нияз гына йокламый. «Дәү әни, син миңа күп кәҗәле, күп сарыклы озын әкият сөйләп кара әле. Алайса күзләремнең йомыласылары килми», – ди ул дәү әнисенә.

Нияз мәзәкләрен Земфира апагыз ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА сөйләде.




*Рәссам Диләрә НӘҮРУЗОВА*











Әйт әле, бу ике әйбер бер-берсенә кайсы яклары белән охшаган? Һәм кай яклары белән аерыла болар?





Яшь тикшерүчегә ярдәм ит: бу эзне кем калдырган?



Абый



Бабай



Әти




Күрше






**Кайсы яхшырак оча: тавыкмы, аккошмы?**










**Наилә өенә кайтканда сәгатьнең теле – 7 дә, минут күрсәтә торган тел – 3 өстендә иде. Наилә өенә сәгать ничәдә кайткан?**

*ЗИЛӘ рәсемнәре*




Дускай! Казандагы 141 нче мәктәп укучылары ясаган рәсемнәр синең күңеленә хуш килер дип ышанабыз.



Ксюша ГРЕБЕНЩИКОВА, 12 яшь.



Ангелина ЕГОРОВА, 10 яшь.




Айгөл ШӘМСЕТДИНОВА, 13 яшь.



КОЛОСОВА (исеме, яше күрсәтелмәгән).



Лилия МИРГАЗИЗОВА, 12 яшь.



Катя КНАЙНОВА, 13 яшь.




Лиза КАЛИНИНА, 11 яшь.

# Башваткыч

## «Тырышкан табар...»


1. Миннән дә биегрәк сикерә.
2. Күтәреп була, ыргытып булмый.
3. Малай су анасының нәрсәсен урлый?
4. Артында себерке, алдында сәнәк.
5. Татар халкының яраткан ризыгы.
6. Песинең дошманы.
7. Балык һәм шәһәр исеме.
8. Караңгыда нәрсә кирәк?
9. Бер туп йөз кат күлмәк кигән.
10. Бушка килә, акча түләп кенә китә.
11. Бер бүкәндә җиде тишек.
12. Өрми, тешләми, өйгә кертми.
13. Урман сарыгы (Г.Тукайча).
14. Белем бирә торган урын.
15. Укырга өйрәтә торган китап.
16. Армый-талмый, кеше артыннан калмый.
17. Иртән туа, кояш чыккач югала.
18. Армый-талмый, трактор артыннан калмый.
19. Ике хәрефле елга.
20. Балык.
21. Авызы юк, теле юк – сөйли.
22. Авылда иң зур бәйрәм.
23. Ике тау арасы.
24. Бакчада үсүче «туп».
25. Башны ваттыра – җавап таптыра.
26. Нәрсәне җирдән алып булмый.
27. Йокы чүлмәге (ерткыч хайван).
28. Батырны нәрсәдән ясыйлар.

*Төзеде: 6 яшьлек Булат БАҺАУТДИНОВ (Казан), әтисе ярдәм итте.*





# ИНГЛИЗЧӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛ




Hello, my name is Marat!
[Хэллоу, май нэйм из Марат]
Сәлам, минем исемем Марат!



This is Kamil. He is my friend.
[Вис из Камил. Хи из май фрэнд]
Бу – Камил. Ул минем дустым.

*БИРЕМ: Камил рәсем ясарга ярата. Менә хәзер дә нинди матур төнге күренеш ясаган.*

*Шул рәсемдә ничә йолдыз бар икәнен санап карыйк әле...*




This is Aliya. She is my sister.
[Вис из Алия. Ши из май систэ]
Бу – Алия. Ул минем апам.

*БИРЕМ: Күрәсеңме, Алия сиңа ниндидер хәрефне күрсәтеп тора. Шуны чәчәкләр арасыннан табып, нинди хәреф икәнен әйтеп бир. Ул нинди төстә?*

*ЗИЛӘ рәсемнәре*




# Саран бака

Борын заманда, бик матур зәңгәр күл буенда, бер бака яшәгән. Бик саран һәм комсыз булган ул. «Күлгә мин хуҗа, күл янына килмәгез», – дип барча су җәнлекләрен куа икән. Хәтта су эчәргә дә ирек бирми икән. Җәнлекләр аның комсызлыгыннан туеп, күлне ташлап китә башлаганнар. Тора-бара комсыз бака берьялгызы яшәп калган. «Бак-ка-ка, бак-ка-ка, бу сулар минеке генә», – дип кычкыра икән.

Көннәрдән бер көнне, күл янына килеп, бер нәни йомран баласы су эчә башлаган. Бака җикеренергә тотынган:

– Бу минем су, бер тамчысын да эчәргә рөхсәт юк, – дип йомранны куа икән. Йомран баласы китәргә теләмәгән, ә бака, суын җәлләп, йомран баласына бирмәс өчен, үзе комсызланып эчәргә тотынган. Эчкән дә эчкән, эчкән дә эчкән. Үзе кабара да кабара икән. Кабарган, кабарган да бака шартлаган. Күлдән киткән җәнлекләр әкрен-әкрен кире кайта башлаганнар. Хәзер барчасы дус һәм тату яшиләр икән.

Алмаз ШӘКЕРТҖАНОВ, 11 яшь.
Кукмара, 4 нче урта мәктәп.



*Мөхәммәт ЛОТФУЛЛИН, 6 яшь,*
*Казан, 77 нче балалар бакчасы.*


Сәләват күпере

**2(215) — 2008**


татмедиа

ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:
«ТАТМЕДИА» АЧЫК АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ.
Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.

УЧРЕДИТЕЛЬ: ОАО «ТАТМЕДИА».
Журнал основан в 1990 году.
На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Баш мөхәррир урынбасары
Нәфис ИСХАКОВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

*Тышлыкта Светлана ПРИВИНА рәсемнәре.*

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кечә яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г.Казань, ул.Муштари, 14.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-Пресс» ААЖ.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 26.02.2008 ел.
Басарга кул куелды 26.02.2008 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тираж 11598 данә. Заказ Т-150.

Санны әзерләүчеләр:
З.Хөснияр, В.Нуриев, Л.Лерон, Ф.Муллахмәт, М.Галиев, Н.Шаһиев, З.Вакказова, Г.Сабирова.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Без йөрмибез
Җилләр куып –
Без йөрибез
Чаңгы шуып!

Кирәк түгел
Таяклар да –
Тимераяк
Аякларда!

